# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 13 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2012, 8 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнарының һәм көчләренең эшләү режимы – гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеген оештыруның вәзгыятькә, гадәттән тыш хәл куркынычы янауны фаразлауга һәм гадәттән тыш хәл барлыкка килүгә бәйле рәвештә билгеләнә торган тәртибе һәм югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә әлеге органнар һәм көчләр тарафыннан көндәлек эшчәнлек режимында үткәрелә торган төп чаралар;

гадәттән тыш хәлгә карата чара күрү дәрәҗәсе (алга таба – чара күрү дәрәҗәсе) – Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнарының һәм көчләренең гадәттән тыш хәлләрнең классификациясенә һәм гадәттән тыш хәлнең үзгәрүе характерына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлдән яклау буенча өстәмә чаралар күрүне таләп итә торган гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә әзерлеге торышы.";

2) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ статья өстәргә:

"$8^1$ статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты компетенциясе**

Татарстан Республикасы Президенты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү;

федераль законда билгеләнгән тәртиптә чара күрүнең төбәк (муниципальара) дәрәҗәсен билгеләү.";

3) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү;

федераль законда билгеләнгән тәртиптә чара күрүнең җирле дәрәҗәсен билгеләү.";

4) 11 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының состав өлеше булган гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы төзелә. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы идарә органнары һәм көчләре эшләве федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 29 сентябре
№ 67-ТРЗ